# КАРАР

## Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Родники торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

31.10.2025 г. № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 18 статьясына туры китереп 2025 елның 31 октябрендә узган гражданнар җыенының нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде, түбәндәге сорау буенча «Сез 2026 елда Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге территориясендәге Родники авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокла хезмәткә алынучы гражданнардан,МХО да катнашучылардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пункт территориясен төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукы булган 107 кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 67 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«ЯКЛЫЙМ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 67 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлегендәге Родники авыл торак пунктында гражданнар җыены булып узды дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга: «Сез 2026 елда Алексеевск муниципаль районының «Родники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Родники авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым

кертү белән килешәсезме, 1 төркем инвалидлардан,көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан,МХО да катнашучылардан тыш, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Родники авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Родники авыл җирлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Родники авыл җирлеге башлыгы Е.А. Яковлева